| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09 ноябрь, 2022 ел Олы Подберезье авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кече Подберезье авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Кече Подберезье авылы, Зур Кызыл урамы, 14Б адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында 2022 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье торак пунктында ТР, Кайбыч районы, Кече Подберезье авылы, Зур Кызыл урамы, 14Б адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында 2022 елның 29 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Кече Подберезье торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы О.М. Емельянова